**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында» 2015 елның 7 февралендәге ПУ-105 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы ПУ-365 номерлы, 2017 елның 31 июлендәге ПУ-661 номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге ПУ-300 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.Т. Борһановны, В.В. Лунинны, С.В. Юшконы чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Казаков Юрий Михайловичны – «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Миңнеханов Рифкать Нургали улын – «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча);

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Шәйхетдинов Роман Александровичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

В.П. Ивановның – «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – фән буенча урынбасары (килешү буенча)»;

А.В. Клименконың – «Россия фәнни фондының Президент программасы буенча эксперт советы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 05 февраль
№ ПУ-98